ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

3 ноябрь, 2021 ел № 9/4

Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 24/6 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

««Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында Федераль закон»га һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы:

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында» 24/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/14, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/12 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1)1 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга айлык акчалата түләү күләме, 2 нче кушымтада каралган тәртиптә;»;

2. Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләүне формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1)2 нче бүлек исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү»

2) 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пунктчалар өстәргә:

«4) Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары;

5) Контроль-хисап палатасы аудиторлары.»

3) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә. Еллык түләүле ял дәвамлылыгы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә исәпләнә. Төп еллык түләүле ял  30 көн тәшкил итә.»

4) түбәндәге эчтәлекле 8.1-8.3 пунктларын өстәргә:

8.1. Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасарына ай саен акчалата түләү һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла. Шул ук вакытта айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме шәһәр Хакименә айлык акчалата түләүләрнең 0,48 артмаска тиеш.

8.2 Контроль-хисап палатасы аудиторына ай саен акчалата түләү һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарыла. Шул ук вакытта айлык акчалата түләүләрнең җыелма күләме шәһәр Хакименә айлык акчалата түләүләрнең 0,30 артмаска тиеш.

8.3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга айлык акчалата түләүләр һәм бүләкләү күләме арту ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнеп хисаплана»;

5) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, лаеклы ялга чыгу сәбәпле эштән киткәндә, муниципаль вазыйфада стаж, дәүләт һәм муниципаль хезмәт стажы 10 елдан артык булганда, биләгән вазыйфасы буенча ун тапкыр айлык акчалата түләү күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк түләнә.»;

6) кушымтадагы 2 нче таблицага түбәндәге эчтәлектәге юллар өстәргә

| | |
|---|---|
| Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары | 31 735 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 25 411 |

7) 3 нче кушымтада:

- «Вазыйфаларның исеме» баганасындагы 5 нче юлда «Контроль-хисап палатасы Рәисе урынбасары» сүзләрен төшереп калдырырга;
- «Вазыйфаларның исеме» баганасындагы 8 нче юлда «Контроль-хисап палатасы аудиторы» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге Карар 2021 елның 30 сентябреннән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В.Шливега йөкләргә.




Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев